| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 27.11.2015 г. Казань № 10-33/кс

«Торак-коммуналь хуҗалыгы баш идарәсе» акционерлар җәмгыяте өчен эчергә яраклы суга, техник суга, су бүлүгә, салкын суны транспортировкалауга һәм ташландык суларны транспортировкалауга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ санлы Федераль законга, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны исәпләп чыгару буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» тарифлар буенча Федераль хезмәтнең 2013 елның 27 декабрендәге № 1746-э санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Торак-коммуналь хуҗалыгы баш идарәсе» акционерлар җәмгыяте өчен эчергә яраклы суга, техник суга, су бүлүгә, салкын суны транспортировкалауга һәм ташландык суларны транспортировкалауга тарифларны билгеле бер календарь чорларына бүлеп, әлеге карарның 1 кушымтасы нигезендә билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар үз көченә кергән көннән алып 2016 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. «Торак-коммуналь хуҗалыгы баш идарәсе» акционерлар җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 санлы карары белән расланган су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән алып 30 календарь көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасының
тарифлар буенча дәүләт
комитетының 27.11.2015 № 10-33/кс
карарына кушымта

«Торак-коммуналь хуҗалыгы баш идарәсе» акционерлар җәмгыяте өчен билгеле бер календарь чорларына бүлеп эчергә яраклы суга, техник суга, су бүлүгә, салкын суны транспортировкалауга һәм ташландык суларны транспортировкалауга тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы оешма | Эчергә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | | техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | | су бүлүгә тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | | салкы суны транспортировкалауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | | ташландык суларны транспортировкалауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Карарның үз көченә кергән көннән алып 2015 елның 31 декабренә кадәр | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр | Карарның үз көченә кергән көннән алып 2015 елның 31 декабренә кадәр | с 01.01.2016 по 30.06.2016 | с 01.07.2016 по 31.12.2016 | Карарның үз көченә кергән көннән алып 2015 елның 31 декабренә кадәр | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр | Карарның үз көченә кергән көннән алып 2015 елның 31 декабренә кадәр | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр | Карарның үз көченә кергән көннән алып 2015 елның 31 декабренә кадәр | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр |
| | Казан шәһәре | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1 | «Торак-коммуналь хуҗалыгы баш идарәсе» акционерлар җәмгыяте | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1 | Лаеш муниципаль районы, Яшел үзән шәһәре, города, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге кулланучылары | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.1.1 | Халык (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 26,46 | 26,46 | 27,67 | | | | 14,68 | 14,68 | 14,81 | | | | | | |
| 1.1.2 | Башка кулланучылар | 22,42 | 22,42 | 23,45 | | | | 12,44 | 12,44 | 12,55 | | | | | | |

| № п/п | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм су бүлүне башкаручы оешма | Эчергә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | | техник суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | | су бүлүгә тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | | салкы суны транспортировкалауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | | ташландык суларны транспортировкалауга тариф (бер ставкалы), сум/куб.метр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Карарның үз көченә кергән көннән алып 2015 елның 31 декабренә кадәр | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр | Карарның үз көченә кергән көннән алып 2015 елның 31 декабренә кадәр | с 01.01.2016 по 30.06.2016 | с 01.07.2016 по 31.12.2016 | Карарның үз көченә кергән көннән алып 2015 елның 31 декабренә кадәр | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр | Карарның үз көченә кергән көннән алып 2015 елның 31 декабренә кадәр | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр | Карарның үз көченә кергән көннән алып 2015 елның 31 декабренә кадәр | 01.01.2016 алып 30.06.2016 кадәр | 01.07.2016 алып 31.12.2016 кадәр |
| | (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | | | | | | | | | | | | | | | |
| 1.2 | Биект тау муниципаль районы кулланучылары (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | | | | 33,06 | 33,06 | 34,39 | | | | | | | | | |
| 1.3 | Казан шәһәре муниципаль берәмлеге кулланучылары (тарифлар НДСтан тыш күрсәтелгән) | | | | | | | | | | 9,18 | 9,18 | 9,18 | 5,81 | 5,81 | 5,89 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 маддәсе 6 пунктын гамәлгә ашыру максатыннан чыгып бүлеп бирелә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны кабул итү,
оештыру һәм җайга салу бүлеге